**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге**

**КАРАР** **КАРАР**

**09.11.2021 ел** **№4**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә, авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Сарысаз-Тәкермән авылы мәдәният йорты бинасында 2021 елның 19 ноябренә 11.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлар, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Сарысаз-Тәкермән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 2022 елда үзара салым акчасын 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Сарысаз-Тәкермән торак пункты зиаратына койма тоту өчен төзелеш материаллары сатып алу;

2.Сарысаз-Тәкермән торак пункты урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);

3. Сарысаз-Тәкермән торак пунктында Беларусь-МТЗ 82 махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
4. СарысазТәкермән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын җыештыру;
5. Сарысаз-Тәкермән пунктында Бөек Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел, Сабантуй бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр алу;
6. Сарысаз-Тәкермән торак пункты өчен генератор сатып алу;
7. Янгын ранцы (1 данә), янгын краннары ( 2 данә) сатып алу.

"ӘЙЕ" “ЮК”.

3. Әлеге карарны Иске Имән авылы җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән 7 көн эчендә урнаштырыга.
4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Имән авыл җирлеге башлыгы: Р.Ә.Исламова